ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1484 от «27 » 11 2017 г.

2018 елга гомуми белем бирү оешмалары
укучыларын махсус билгеләнгән автобуслар
белән йөртүне оештыру буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүбәясе нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 5 июлендәге “Мәктәп балаларын транспортта йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары турында” 545 нче санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. 2018 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүбәясе нормативларын расларга;

2018 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (А.М. Сергеев) гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.К.Мөхәммәтҗанов

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.11.2017 ел, 1484 нче санлы
карарына 1 № лы кушымта

2018 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе атамасы | Ике ставка нормативының күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сумнарда | автотранспорт чарасының бер чакрымына ставкасы, сумнарда |
| КАВЗ | 104691 | 33,53 |
| ПАЗ | 104948 | 33,52 |
| ГАЗ «Газель» | 99417 | 28,22 |
| УАЗ | 98964 | 27,10 |
| FIAT | 98707 | 26,10 |
| Peugeot Boxer | 99222 | 25,73 |
| Ford Transit | 100046 | 28,11 |

Җитәкче урынбасары В.И.Никитин

Приложение
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.11.2017 ел, 1484 нче санлы
карарына 2 № лы кушымта

# Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).
1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында фактик пробегы нигезендә исәпләнә.
1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.
1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик пробегы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында автотранспорт чарасының хисап елы өчен фактик пробегы буларак кабул ителә.

## 2.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең исәп-хисабы.

2.1. Муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:
$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;
$n_{f\,m}$ - моделе автотранспорт чараларының фактик пробегы, километр;
$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен
махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы,

бер километрга, сум;

$NF_{asm}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны транспортта йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сум;

$M_m$ - количество автотранспортных средств модели $m$, единиц;

$m$ - m моделе ,автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.

Җитәкче урынбасары В.И.Никитин